Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN

УНИВЕРСИТЕТ

12+

№27 (78)

12 сентябрь 2013 ел

## • Вакыйгалар эзеннән

**9 СЕНТЯБРЬ** көнне ректор **И.ГАФУРОВ** җитәкчелегендә яңа уку елының **БЕРЕНЧЕ РЕКТОРАТ УТЫРЫШЫ** узды. Җыелыш тантаналы башланды – XXVII Җәйге Универсиадада җиңүче һәм призерлар булган КФУ студентларын тәбрикләделәр. Алар барлыгы ун медаль яуладылар. Шуларның дүртесе – алтын, берсе – көмеш һәм бишесе – бакыр. Соңрак ректорат әгъзалары фаҗигале рәвештә вафат булган юридик факультет профессоры **МИХАИЛ ЧЕЛЫШЕВНЫ** бер минутлык тынлык белән искә алдылар. Ректор тәкъдиме буенча, мәрхүмнең ятим калган кызына КФУ бюджетыннан ай саен 10 мең сум күләмендә компенсация түләнәчәк. Аннан контроль йөкләмәләр үтәлеше һәм чаралар планы хакында Административ эшчәнлек буенча проректор – аппарат җитәкчесе **А.ХАШОВ** җиткерде. Институт-филиаллар һәм факультетларның конкурентлылыгын арттыру буенча юл карталары һәм КФУ идарәсе органнарындагы үзгәрешләр белән Икътисад һәм стратегик үсеш мәсьәләләре буенча проректор **М.САФИУЛЛИН** таныштырды. РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы конкурсы шартлары буенча университет структурасына өстәмә рәвештә тагын ике коллегиаль идарә органы өстәлергә тиеш: Программа дирекциясе һәм Халыкара фәнни совет. Ректор, үз чиратында, мондый советларны барлык институт һәм факультетларда булдырырга тәкъдим итте. КФУга чакырылган чит ил укытучылары һәм галимнәре өчен, Казанда 50 фатир биреләчәк, шул ук максаттан Универсиада Авылының бер корпусын да яңадан җиһазландырырга җыеналар. Ректор утырышны яшь галимнәр өчен ипотека кредиты программасы хакындагы мәгълүмат һәм Ерак Көнчыгыш федераль округы җирле халкына ярдәм күрсәтү, бу төбәкнең мәгариф системасын торгызуга акчалата ярдәм итү тәкъдиме белән тәмамлады.

• • • •

**9 СЕНТЯБРЬ** көнне ректор **И.ГАФУРОВ** һәм **ИНСТИТУТ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ «РОСТЕХНОЛОГИЯЛӘР» ДӘҮЛӘТ КОРПОРАЦИЯСЕ ВӘКИЛЛӘРЕ** белән очрашты. Корпорация уку йортларында шул өлкә буенча белгечләр әзерләү, махсус предметлар булдыру, уртак фәнни-тикшеренү эшләре башкаруны максат итеп куя. Очрашу барышында ике арада хезмәттәшлек булдыру турында сүз барды.

• • • •

Шул ук көнне **КФУ ҖИТКӘКЧЕЛЕГЕ** Сәламәтлек һәм медицина тикшеренүләре **ФРАНЦУЗ МИЛЛИ ИНСТИТУТЫ ВӘКИЛЛӘРЕ** белән очрашты. Шулай ук ике арада килешү төзү турында сүз барды.

• • • •

Кичә Физика институтында Осло университетының Информатика институты профессоры **СВЕРРЕ ХОЛЬМА** «Медицина ультратавыш диагностикасы» темасына **АЧЫК СЕМИНАР** үткәрде. Галим 13 сентябрь көнне дә белем бирүен дәвам итәчәк. Бу көнне һәр теләгән кеше Кремль, 16а адресы буенча урнашкан бинаның 210 ауд. 16:00 сәгатьтә «Эластометрия – физика, җиһаз һәм модельләштерү» дигән семинарда катнаша ала.

• • • •

**10 СЕНТЯБРЬДӘН 10 ОКТЯБРЬГӘ** кадәр КФУның Иҗтимагый студент оешмалары һәм берләшмәләре координацион советы **ХАБАРОВСК КРАЕНДА СУ БАСУ ВАКЫТЫНДА ЗЫЯН КҮРҮЧЕЛӘРГӘ ЯРДӘМ ИТҮ АКЦИЯСЕ** уздыра. Көнкүреш кирәк-яракларын УНИСКның 117 кабинетына һәм Кызыл Позиция, 2а адресы буенча урнашкан 4 номерлы тулай торакка китерергә мөмкин. Әйберләр яңа булырга тиеш. Белешмәләр өчен телефон: 8 (843) 238-77-90, 292-72-70.

• • • •

Өзлексез белем бирү институтының **«ЗАМАНЧА ФИЛОЛОГИЯ» УКЫТУ ҮЗӘГЕ ТЕЛ КУРСЛАРЫНА ТЫҢЛАУЧЫЛАР** кабул итә. Биредә «Һөнәри коммуникация өлкәсендә тәрҗемәче», «Бөтен кеше өчен дә инглиз теле», «Телдән тәрҗемә итү: теориядән гамәлгә», «Итальян теле», «Гид-тәрҗемәче» һәм «Польша теле» буенча курслар эшли. Тулырак мәгълүматны 292-88-57 телефоны аша белергә мөмкин.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Александра Киреева фотосы

# «Ул иң яхшылардан санала!»

**Алинә САДЫЙКОВА,** хәбәрче

10 сентябрь көнне КФУның Тарих музеенда 45 кеше тантаналы рәвештә халыкара сертификат иясе булдылар. Аларны КФУ ректоры Илшат Гафуров һәм Россия Фәннәр академиясенең Фәнни совет рәисе урынбасары Амет Володарский тәбрикләде.

Әлеге бәхетлеләр арасында университет укытучылары, студентлар һәм мәктәп укучылары да бар иде. Алар барысы да Кембридж үзәгендә The Teaching Knowledge Test (TKT) һәм Cambridge Certificate in Advanced English (CAE) курсларында әзерлек узганнар һәм уңышлы итеп имтихан тапшырганнар. Бу сертификатлар тел буенча югары һәм профессиональ әзерлек турында сөйли, күп илләрнең университет һәм төрле компанияләрендә югары бәяләнә.

Мәскәү чит телләр институты Кембридж үзәгенең субцентры Казанда 2009 елда ачыла. Шул вакыттан бирле йөз илледән артык кеше сертификат алган. Имтиханнарны уңышлы тапшыручылар арасында КФУ студентлары, аспирантлары һәм укытучылары белән беррәттән, башка төбәк һәм университет вәкилләре дә бар.

Тарих музеендагы тантананы **И.Гафуров** башлап җибәрде. Ул чарада катнашучыларны сәламләде һәм безнең университетта шундый алдынгы карашлы яшьләр белем алганына сөенгәнен әйтте: «Шунысын белегез: бу әле сезнең бөек җиңүләрегезнең башы гына. Алга таба тагын да зуррак үрләр, куйган максатларга ирешү тора!»

**А.Володарский** университетыбыз эшчәнлеген югары бәяләде: «КФУдан өйрәнер әйберләр күп. Мин читтән генә булса да аның ничек уңай якка үзгәргәнен күзәтеп барам. Казан университетының белем бирү модернизациясе турында фикер алышуда лаеклы урын алып торуы – бик куанычлы күренеш». Алга таба ул Кембридж сертификатының бүгенге көндә ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын билгеләп үтте: «Хәзерге вакытта, Кембридж университыннан кала, Европа дәрәҗәсендәге сертифакт бирә алырдай үзәк башка юктыр. Ул иң яхшылардан санала. Чын инглиз университеты катырыгына биреп калмый, ә сезнең 150 елдан артык эшкәртелгән билгеле бер дәрәҗәдәге белемнәргә ия булуыгызны раслап тора».

Мондый матур сүзләр һәм теләкләрдән соң, тантананың төп өлеше – бүләкләүгә күчтеләр. CAE буенча – 11, TKT буенча 34 кешегә сертификатлар тапшырылды.

Үзәкнең барлык укучылары исеменнән Айрат Зарипов, мондый зур мөмкинлек биргәннәре өчен, И.Гафуров, А.Володарский һәм Филология һәм сәнгать институты директоры Р.Җамалетдиновка рәхмәт сүзләре җиткерде. «Бүген мин үзем белән генә түгел, ә барлык укытучыларым белән дә горурланам. Алар ярдәме белән, без белемнәребезне халыкара дәрәҗәдә күрсәтә алдык. Рәхмәт сезгә!».

## • Уртак җиңү

# КФУ дөньякүләм таныла!

QS WORLD UNIVERSITY RANKINGS

КФУ дөньяның иң яхшы югары уку йортлары исемлегенә керде. Рейтинг 2013 ел өчен QS Quacquarelli Symonds Британия компаниясе тарафыннан төзелде.

QS 2004 елдан бирле бу исемлекне бастырып килә. Беренче өчлекне Массачусет технология институты, Гарвард университеты һәм Кембридж университеты алып тора. КФУ узган ел белән чагыштырганда, берничә басычка югары күтәрелеп, 800 уку йорты арасында 601-650 позициясен алып тора.

Безнең уку йортының әлеге рейтингның беренче йөзлегенә эләгү мөмкинлеге дә зур, чөнки уку йортыбыз тагын да камилләшү юнәлешендә зур эш башкара: алдынгы чит ил уку йортлары, рейтинг төзи торган агентлыклар белән килешүләр төзи, инфраструктураны үстерә, халыкара басмаларда фәнни мәкаләләр бастыруны арттыра. Уку йортының йөзләп лабораториясен дөнья күләмендә иң яхшылар дияргә мөмкин.

*Тышкы эшләр департаменты мәгълүматлары файдаланылды*



● Юбиляр

# Зур бәхет мизгелләрдән җыела

Филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан фәннәр академиясе, Халыкара информатизация академиясе, Гуманитар фәннәр академиясе, Халыкара педагогика академиясе академигы, Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстан АССРның атказанган фән эшлеклесе, Татарстанның Югары Советы депутаты, Татарстанның Республика партиясе председателе Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсупов бу көннәрдә үзенең олы юбилеен билгеләп үтә.



## Кояш балачактан чыга

Ул – авыл малае. Кайчандыр Казан артындагы Мәңгәр волостена кергән Кышкар (Наянгуш) авылында дәһшәтле Ватан сугышы алдыннан гади крестьян гаиләсендә туган.

Ике катлы мәһабәт таш мәчет бинасында урнашкан мәктәптә Рүзәл җиде класс тәмамлый. Аның балачагы, үсмер чоры авылда туып үскән күп меңләгән сугыш еллары балаларыныкы кебек, авырлыкта уза. Әти-әнисе гади крестьяннар була. Әтисе – авыл кешеләре әйткәнчә, «Йосып Абдуллаҗаны» – фин сугышын «татып» кайтып, Ватан сугышы фронтында берничә ел булып, яраланып, өйгә 1945нче елның язында гына кайтып керә. Дүрт малайны тәрбияләп үстерү әни җилкәсендә була...

Җиде классны тәмамлаганлыкка алган, тырышып укыган, макстатчан Рүзәлгә мәктәпне «бишле»гә тәмамлаганы өчен Мактау грамотасы бирергә кирәклеген «оныталар», ансыз исә техникумга кабул итү имтиханнарын бирәсе була. Татар авылында җиде классны татарча тәмамлаган малайга русча имтихан бирү мөмкин эшме икән соң ул заманда? Шулай да ул, таныклыгын кесәгә тыгып, беренче мәртәбә Казан каласына юл тота.

## Яшьлек – яңарыш

14 яше дә тулмаган малайның, мөстәкыйль тормышы менә шулай башланып китә. Техникумны үзе эзләп таба, көч-хәл белән гариза яза һәм авыл сәүдәсе өчен товар белгече, бухгалтер, икътисадчы-плановиклар әзерли торган урта махсус уку йортына – Казан кооперация техникумына керә. Бик кырыс шартларда товароведлык һөнәрен үзләштерә.

Техникумны тәмамлагач, әле 17 яше дә тулмаган белгечне Курган өлкәсенә бер райпотребсоюзга товаровед итеп җибәрәләр. Аның кайда эшлисе тиз хәл ителә. «Сине иң интернациональ районга – Усть-Уйка райпотребсоюзына җибәрәбез», – диләр. Усть-Уйка чынлап та руслардан тыш, украиннар, казаклар, себер татарлары, молдаваннар, немецлар, тагын әллә нинди милләт вәкилләре яши торган чын интернациональ район була.

Вакыты җиткәч, Рүзәл армиягә алына һәм Таҗикстанда хәрби хезмәттә була. «Ватан алдындагы бурычны үтәдем, ирекле тормышның кадерен белергә өйрәндем», – ди Рүзәл тормыш китабының әлеге бүлеге турында искә алып.

## Милләт җанлы егет

Аның эченә яшьтән үк миллилек корты кергән булган. Курганда эшләгәндә дә, армиядә хезмәт иткәндә дә татар җырларын сагынып яши, шигырьләр (әлбәттә, татарча) язгалый. Армиядә чагында ук аның башына «мин татар телен һәм әдәбиятын яхшы итеп өйрәнергә тиеш», дигән уй керә. Ул уй торган саен ныгый бара һәм Рүзәл, ниһаять, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетындагы татар теле һәм әдәбияты бүлеге студенты булу бәхетенә ирешә.

Кызык хәл: ул елларда (60 нчы еллар башы) күп кенә татар егет-кызларында ниндидер бер күтәренке милли рух булган. Төркемдәге егетләрнең күбесе, армиядә булып кайтып, кызлар да 2-3 ел эшләп килгән максатчан, җитди яшьләр. Хәзер аларның күбесе – татар мәдәнияте үсешенә лаеклы өлеш керткән күренекле шәхесләр. Р.Фәйзуллин, Ф.Зыятдинов, Ш.Маннапов, Ф.Гарипова, Ф.Баязитова, Л.Җамалетдинов, Ш.Асылгәрәев, Ә.Шәриповлар – әлеге төркемдә укыган язучылар, галимнәр, җәмәгать эшлеклеләре.

Профессор М.З.Зәкиев татар теле кафедрасы мөдире итеп куелганнан соң, аның инициативасы белән факультетта бер әһәмиятле яңалык кертелә. Кайбер студентларны, теләкләре буенча, үзенчәлеклерәк сәләтләренә карап, өченче курстан индивидуаль план белән укыта башлыйлар. Рүзәлне, «Тәрҗемәче-филолог» дигән квалификация бирү өчен, махсус план буенча укыталар һәм ул шундый квалификация дипломы алып чыга. Шушы хәл Рүзәлнең алдагы эшләрендә хәлиткеч роль уйный.

Башта аны Татарстан радиосына тәрҗемәче итеп эшкә алалар. Аннары Казан телевидениесенең пропаганда редакциясе мөхәррире булып эшли. Телевидениедә эшләү еллары бик бәрәкәтле, нәтиҗәле, алдагы тормышы өчен яхшы әзерлек чоры була.

Университетны тәмамлаганда, Рүзәлнең диплом эше җитәкчесе профессор М.З.Зәкиев аспирантурада калырга тәкъдим итә. Ләкин ул, бераз эшләп алырга кирәк әле, дип, әдәпле генә баш тарта. Алайса, берадан килерсең, дип сүзеннән кайтмый Мирфатыйх ага. Һәм чыннан да М.З.Зәкиев, Казан педагогика институтына проректор булып күчкәч, аннары тиздән ректор булгач, Рүзәл Юсуповны аспирантурага чакырып ала. Рүзәл кандидатлык диссертациясен 1970 елда вакытыннан алдарак яклый һәм ректор аны тарих-филология факультетының татар теле кафедрасына өлкән укытучы итеп эшкә ала...

## Хакыйкать кошы

Докторлык диссертациясе язу, фәннәр докторы дигән гыйльми дәрәҗә алу, аннары тиздән профессор исеме бирелү Рүзәлнең эшендә һәм, гомумән, тормышында җитди борылышларга нигез була.

Факультетта, кафедрада эше әйбәт кенә бара һәм тиздән ул, ректор тәкъдиме белән, тарих-филология факультетының деканы итеп сайлана.

1986-2002 еллар – Р.А.Юсуповның ректорлык чоры – Казан педагогика институты (университеты) өчен, чын мәгънәсендә, реформа еллары була. Вуз нык үзгәрә, сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да күзгә күренеп үсә.

1989-1990 елларда, халык депутатларының Казан шәһәр советына депутат итеп сайлангач, мәгариф комиссиясе белән җитәкчелек итә. 1990 елда Р.Юсупов – ТР Югары Советы депутаты. Биредә ул парламентның милли мәсьәләләр һәм мәдәният комиссиясе рәисе вазифаларын башкара: Татарстан халыклары телләре турында закон проектын төзүдә катнаша, аны закон итеп кабул итүгә әзерли. Республикабызда иң әһәмиятле, иң хәлиткеч вакыйгаларның берсе – Татарстанның дәүләт суверенитеты Декларациясен кабул итүне башлап йөрүчеләрнең берсе дә Р.А.Юсупов була. ТРның яңа Конституциясе проектын әзерләү эшендә дә катнаша.

## Бәхет сере

Бәхет югары дәрәҗәдә, күп итеп хезмәт хакы алып эшләүдә генә түгел... Аның өчен нык нигезе, ышанычлы кешеләре булган гаилә кирәк. Рүзәл бу яктан да бик бәхетле. Яшьлек мәхәббәте Олы Мәңгәр кызы Дилара белән төзелгән гаилә – Рүзәлнең арка таянычы, ышанычлы тылы. Тырыш, акыллы хатыны белән, Аллага шөкер, бүген дә бик бәхетле яшиләр.

Уллары Фәнис, кызлары Диләфрүз туа. Йөрәк парәләре Фәнис утыз яше тулганда, фаҗигале рәвештә вафат була. Баланы яшь килеш югалтудан да авыррак нәрсә юктыр... Исенә төшкән саен, Рүзәл аганың йөрәге әле дә өзгәләнә. Фәридә исемле оныклары ятим кала.

Кызлары Диләфрүз кияүләре Айдар белән мул тормышта ике малай – Ислам һәм Кәримне – дәү әтиәниләренең кадерле оныкларын үстерәләр.

***Редакциядән.*** *Рүзәл Абдуллаҗанович бүгенге көндә дә актив рәвештә татар телен фәнни эшкәртүдә армый-талмый хезмәт куя. Ел саен күп санлы мәкаләләр, монографияләр чыгара. 2013 елның 12 июленнән татар телендә дөрес сөйләү, язу мәсьәләләре турында бик борчылып, «Ватаным Татарстан» газетасында тел культурасына багышланган рубрика ачып җибәрде. Хөрмәтле остазыбыз! Юбилеегыз уңае белән Сезгә нык сәламәтлек, гаилә бәхете телибез һәм һәрдаим шәкертләрегезнең олы ихтирамын тоеп яшәгез!*

***Әнвәр Хуҗиәхмәтов,***
*Педагогика кафедрасы мөдире, педагогика фәннәре докторы, профессор, РАГН академигы, ТРның атказанган фән эшлеклесе, РФ һәм ТР мәктәпләренең атказанган укытучысы, РФ югары мәктәбенең мактаулы хезмәткәре*

● Бездә кунак бар

# Авыллар бер - проблемалар төрле

**Раил САДРЕТДИНОВ,**
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Шушы көннәрдә КФУның Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институтында Токио университеты галиме Фумики Тахари кунакта булып китте.




Бу галим Рәсәй һәм Кытайның җирле үзидарә системасын тикшерү белән шөгыльләнә. Бер елдан артык рус телен өйрәнә, инглиз, кытай, япон телләрендә иркен аралаша. Профессорның чыгышы да инглиз телендә барды. Булачак социологларга һәм журналистларга биргән дәресендә ул үзенең Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы Тәмте авылында һәм Кытай дәүләте авылларында алып барган тикшеренүләре турында бәян итте. Кытай һәм Рәсәй, шулай ук Тамбов өлкәсе белән Татарстан Республикасы авылларында эшнең оештырылуы, борчыган проблемалар турында тәфсилләп сөйләде.

Галим үзе билгеләп үткәнчә, башкарылган хезмәт әлеге илләрнең авыл җирлекләрендә үзидарә системасының төзелешен генә түгел, ә андагы җәмәгать тормышы белән идарә итүнең нинди ресурслар кулланып оештырылуын, авылда формаль булмаган лидерларның кем булуын һәм башка мәсьәләләрне дә үз эченә алган.

Ерак Япония галиме Татарстанның бу авылы турында ничек белгән соң дигән сорау туарга мөмкин. Фумики Тахари бу авылны коллегасы тәкъдиме буенча үз иткән. Шунысы игътибарга лаек: Япония бу тикшеренүне үзе финанслаган.

Тахари үзе тикшеренүләр үткәргән җирлектә 1-3 атна вакытын сарыф итә. Халык белән аралаша, һәрбер өйгә кереп, кешеләрдән үзләрен борчыган проблемалар турында сораша, авыл тирәсен җентекләп тикшерә, авылның картасын төзи. Галим үзе билгеләп үткәнчә, ул тикшеренүләр алып барган җирлеккә берничә елдан соң кабат әйләнеп кайта, үзгәрешләрнең кайсы якка булуын ачыклый. Беренче килгәндә, авыл халкы, авыл җирлеге башлыгы профессорга бик шикләнеп, сәерсенеп караса, икенче килгәнендә исә, халык галим белән иркен аралаша, профессор тагын да яңа нәтиҗәләр чыгара.

Япония галиме, Рәсәйнең Кама Тамагы авылында, Тамбов өлкәсе авыл җирлеге белән чагыштыргандa, яшәү өчен уңайлырак, шартлар яхшырак дигән нәтиҗәгә килә. Мәсәлән, Тамбов өлкәсендә яшәүчеләрнең үзәгенә үткән кышын йортны ягу-җылыту проблемасы бездә юк икән, чөнки һәр өйдә зәңгәр ягулык. Ләкин Рәсәй һәм Кытай авылларының уртак проблемасына килгәндә, бу – юллар. Тик Рәсәй авыл җирлекләренә бюджеттан акча бүлеп бирсә, Кытайда авыллар – спонсорлар җилкәсендә көн күрә икән. Әмма профессор Татарстан авылы өчен аерым бер проблемага туктала – ул да булса, авыл җирлекләре территориясенең чүп-чарга күмелеп ятуы.

Бу һәм башка нәтиҗәләр галимнең Европаның саллы фәнни журналында басылып чыккан мәкаләсендә чагылыш тапкан. Булачак социологларга галим тикшеренергә, халык белән аралашырга, төпле нәтиҗәләр ясарга киңәш итте. Шулай булганда гына уңыш көтәчәген искәртте.

Галимнәребез

# Гадилек һәм бөеклек үрнәге

Галим-голәмәгә киң җәмәгатьчелек арасында танылу, дан-шөһрәт казану җиңел түгел. Әмма Альфред Халиковны олы галим, археолог буларак белмәгән, ишетмәгән татар сирәктер ул.



Халкыбызның килеп чыгышын җентекләп өйрәнгән, шул хакта газета-журнал битләрендә күпсанлы мәкаләләре белән чыгыш ясаган, китаплар язган кеше буларак беләләр аны. А.Х.Халиков 1929 елның 30 маенда Татарстанның Норлат-Октябрь районы Күзкәй (Курманаево) авылында укытучылар гаиләсендә туа. Тиздән аларның гаиләсе Казанга күченеп килә. 1947 елда урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга керә. Археологиягә беренче адымнарын күренекле тарихчы-археолог Н.Ф.Калинин җитәкчелегендә башлый. Үзенең хөрмәтле остазы белән бергәләп, археологик разведкаларда, казу эшләрендә катнаша, ныклап торып фән белән шөгыльләнергә кирәк дигән карарга килә. А.Халиковның студент елларында ук язылып, 1951 елда университетның «Гыйльми язмалар»ында басылып чыккан беренче фәнни хезмәте СССР Югары белем бирү министрлыгы тарафыннан 1 нче премиягә лаек дип табыла. Шул ук елны университетның соңгы курс студенты А.Халиков СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтына лаборант эшенә кабул ителә. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр галим шушы институтта эшли, гади лаборанттан башлап, археология бүлеге мөдире һәм баш фәнни хезмәткәр дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Бирелә аның ургылып торган энергиясе, искиткеч оештыру сәләте моңа кадәр фәндә мәгълүм булмаган дистәләрчә, йөзләрчә археологик истәлекләр ачуга юнәлтелә, Татарстан районнарында һәм күрше өлкәләрдә алып барган нәтиҗәле казу эшләре күпләрне көнләштерерлек фәнни ачышларга китерә.

Альфред Хәсәновичны татар зыялылары Идел-Урал буе халыкларының борынгы ыруглык җәмгыяте чорына караган археологиясен төптән өйрәнгән галим буларак та беләләр. Бу дөрестән дә шулай. СССР Фәннәр академиясенең Археология институтында 1956 елда яклаган кандидатлык диссертациясе дә, 1966 елда яклаган докторлык диссертациясе дә фин-угор халыкларының таш һәм бронза гасырына караган борынгы тарихын өйрәнүгә багышланган иде. Әмма шушы хезмәтләрендә дә галим үзен гаҗәеп киң эрудицияле тарихчы итеп тә (археолог кына түгел) күрсәтә алды. Фин-угор халыкларының этногенезына кагылышлы бик тә катлаулы проблемаларны өйрәнүче галимнәр әле хәзер дә А.Х.Халиков хезмәтләренә таяна. Бәхәсләшәләр дә, билгеле, кайбер фикерләрен кире дә кагалар. Әмма Халиков концепциясенең нигезе нык, чөнки ул искиткеч бай тарихи-археологик чыганакларга таяна.

Профессор А.Х.Халиковның археологиядә якты эз калдырган тагын бер фәнни юнәлеше бар – төрки халыкларның, бигрәк тә болгар бабаларыбызның борынгы тарихы. Бу тарих белән ул утыз елдан артык шөгыльләнде. 1970 елларда А.Х.Халиков бу юнәлештәге фәнни эшчәнлеген тагын да кинәйтә, тирәнәйтә төште. Идел буе төбәгенә төрки кабиләләрнең болгарларга кадәр берничә гасыр элек үтеп керүләрен исбатлап язган фәнни мәкаләләре галимнәрнең кискен тәнкыйть утына дучар булса да, бүгенге көндә Халиков концепциясе беркемдә дә шик уятмый инде. Киресенчә, төрки бабаларыбызны тагын да борынгырак чордан эзли башладылар,

1994 елда А.Х.Халиков Казан Кремлендә яңадан казу эшләренә тотынган иде. Нәтиҗәсен генә күрергә өлгермәде. Татарстан археологиясенең олы казанышы иде бу һәм әлеге уңышларда Альфред Халиковның саллы өлешен танымау хата булыр.

*Мәгълүмат «Мәшһүр татар галимнәре» китабыннан алынды*

Хәйрия эше

# Тамчыдан күл җыела!



Бәла аяк астында йөри, диләр. Нибары 24 яшен тутырган, гомеренең иң матур чорына житкән Регина Мавлетшинага ашыгыч рәвештә ярдәм кирәк.

Табиблар аңа бик куркыныч диаогноз куйды, ләкин ярдәмчел, киң күңелле кешеләр Регинага ярдәм итә һәм дәвалану өчен зур суммадагы акчаны җыярга булыша ала. Изгелек җирдә ятмый, диләр. Әйдәгез, без дә 2011 елда ТДГПУның татар филологиясе факультетын тәмамлаган, бүгенге көндә 146 номерлы мәктәп укучыларына туган телебез серләрен өйрәтүче мөгаллимәгә ярдәм итик. Үзебезгә, якыннарыбызга Ходай исәнлек-саулык бирсен!

**Акча күчерү өчен реквизитлар:**
Банк получателя:
Отделение "Банк Татарстан" 8610
г.Казань
БИК 049205603
ИНН 7707083893
КПП 165702001
К/счет 30101810600000000603
СЧЕТ № получателя:
30301810562006006226

Сәләткә сәбәп кирәк

10 сентябрь көнне УНИКСның Кече залында КФУның төркем старосталары җыелышы узды. Очрашуда социаль һәм тәрбия эшләре буенча проректор Ариф Межведилов һәм студпрофком рәисе Юлия Виноградова катнашты.

# Ул да студент!

**Илмир ВӘЛИЕВ,** хәбәрче

Җыелышның беренче өлешендә старосталарның эшчәнлеге хакында сүз алып барылды. Беренче курс старосталарына бу вазифаның нечкәлекләре һәм нәрсәгә нигезләнүе турында тулырак А.Межведилов сөйләде. «Староста – төркем башлыгы гына түгел, ә җаваплылык, пунктуальлек сыйфатларына, оештыру талантына ия булган студент та», – дип йомгаклады чыгышын проректор.

Староста төркемнең йөзе һәм барысына да үрнәк булырга тиеш. Кем соң ул, гомумән алганда, староста? Бу сорауга җавапны сүзлектән тиз арада эзләп табып була. Староста – ул югары, урта һәм һөнәри уку йортының кайбер административ вазифаларын башкаручы һәм оештыру мәсьәләләрен хәл итүче төркем башлыгы. Студентларга үз старосталары белән дуслык җебен ныгытырга киңәш итәр идем. Кемнең көймәсендә – шуның көендә, дигәндәй күп нәрсә старостадан тора. Әгәр сез аның белән яхшы дуслар икән, парларга килә алмаган очракта, ул хәлеңне аңлар дип уйлыйм. Күп студентлар бу һәм башка мөмкинлекләрне кулдан ычкындырмый. Ләкин «мин староста белән дус», – дип аның җилкәсенә менеп утыру да дөрес түгел. Онытма: ул да синең шикелле үк студент! Синең төркемдәшең!

Кайбер чит илләрдә староста төшенчәсе бөтенләй дә кертелмәгән. Мәсәлән, Америкадагы уку йортларында төркемнәр, гомумән, юк икән. Һәр студент – үзенә үзе хуҗа: теләгән укытучыга язылып, аның дәресенә йөри ала. Бездә, миңа калса, мондый тәртипне кертү бик авыр булыр иде...

Җыелыш барышында кайбер төркем башлыклары белән якыннан танышу мөмкинлеген мин дә кулдан ычкындырмадым. Староста булуның уңайлыклары белән бергә, тискәре яклары да җитәрлек икән!

**Надежда Царева**, Педагогика һәм психология институты: «Староста үз төркеме өчен җаваплы булырга тиеш. Ул төркемдәге барлык студентларга да университет тормышындагы вакыйгалар турында хәбәр итә. Староста булу кайвакыт бик ярдәмгә килә».

**Азалия Закирова**, Идарә һәм территориаль үсеш институты: «Староста – актив, позитив, башкаларны тыңлый белү сәләтенә ия булган студент».

**Динар Вәлиуллин**, Химия институты: «Староста булуның уңай яклары бик күп: бөтен вакыйгадан хәбәрдар, укытучылар белән тыгыз элемтәдә торасың. Староста шулай ук төркемдәге студентлар арасында дуслыкны ныгытучы да!»

**Ксения Алентьева**, Педагогика һәм психология институты: «Әлеге вазифа зур җаваплылык таләп итә. Ул төркемдәге һәр студент һәм деканат белән тыгыз элемтәдә торырга тиеш».



Александра Киреева фотосы

Бер дулкында

# Бишенче тәбикмәк

**Лиана МӘРДАНОВА,**
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Өйгә тәмле ис таралган, тәбикмәк исе. Нык яратам инде шуларны, әни йөзне пешерсә дә ашап бетерер идем кебек. Калориясе генә күп... Иртәгә бишле алам дип, кабат бишенче тәбикмәкне авызга кабыйм гына дигән идем. Будильник шалтырады...

Бер белмәгән җирдә ятам. Матурын матур инде үзе... Искә төште аннан соң. Нинди тәбикмәк индеее, мин бит хәзер студент. Шунлыктан өйдә дә түгелмен. Общагада ятам...

Кичәгене искә төшереп тагын күзгә яшь тыгылды... Йөз дә ун тапкыр өченче катка менеп төшеп, әйберләрне көчкә ташып бетердем. Тапканнар бит, имеш, Универсиада авылына ят кешеләр керергә тиеш түгел. Әнинең керәсе килмиме инде шунда, минем кайда торасымны күрәсе килмиме аның? Менә бөтен әйберне ташып бетердем, хәзер инде әнине кочаклап, әтигә сарылып «Сау бул» гына диясе калды. Тик үкереп елап җибәрдем. Моны күреп әни елый, әти әкрен генә мышкылдап куйды. Белсәң икән, дустым, ничек кыен булганын! Тиз генә бүлмәмә кереп киттем дә тынычланмакчы булам. Тынычланырсың монда?! Гомереңнән 18 елын алар белән бергә үткәр дә?! Үзем елыйм, үзем көләм: «Бигрәк җебек икәнсең, Лиана!» – дим.

Сагынуларымны Спорт сараендагы бәйрәм оныттырды. Андагы халык, андагы матурлык, андагы дәрт, дустым, синең андый бәйрәмне күргәнең булмагандыр! Берсе биергә куша, икенчесе җырла ди, рәхәтләнеп күңел күтәреп кайттык та яттык. Кичен тагын әниләрне искә төшереп мышкылдап алдым. Сагыну да түгел инде ул, әти-әнигә минсез кыендыр кебек...

Студент тормышы шушы икән... Мин хәзер мәктәп укучысы түгел инде. Кайчан гына: «Апа, нигә кошлар җылы якка оча ул? Апаааа, ник аюлар кыш көне йоклый?» – дип парта артында шыңшып утырган булсам, хәзер инде СТУДЕНТ.

Монда барысы да икенче. Дәрес түгел, паралар, 45 минут кына түгел әле алар, бер сәгать ярым! Ул вакыт эчендә карынында бүреләр улый башлый. Йокы бабай да килә, ди өлкән курстагылар, әлегә килгәне юк. Укытучыларыбыз кызыклы итеп сөйли. Әнинең бишенче тәбикмәге еш искә төшә, әлбәттә, ләкин мин бирешмим, үзем пешереп ашадым. Чәй эчәргә килегез. Бездә күңелле! Күңеллесен күңелле инде, ләкин өйдә синең өчен янып-көеп торучы әти-әниеңне онытма. Көненә бер булса да «Хәлләрегез ничек?» –дип сора. Сиңа да, аларга да рәхәт булачак. Кеше кайда гына булмасын, өендәге бишенче тәбикмәген онытырга тиеш түгел.

• Алар бездә укыган

# Илдар Сөләйманов: «365 көн эчендә 365тән артык хәрәкәт ясап карарга кирәк!»

Әңгәмәдәш – **Ләйсән ИСХАКОВА**

Бүгенге яшьләрне ничегрәк бәяләргә була? Әйе, алар сәләтле һәм амбициоз. 24 яшьлек Илдар Сөләйманов моның шулай икәнлеген үз тәҗрибәсендә исбатлый. Ул поп-арт стилендәге портретлар, интерьерны бизәү өчен картиналар ясау белән шөгыльләнә. Илдар бу юнәлештә эшләүче шәхси остаханәсен ачып җибәрергә дә өлгергән. Якын кешесенә беркемдә дә булмаган бүләк ясарга, бүлмәсен үзенчәлекле картиналар белән бизәргә теләүчеләр бирегә еш мөрәҗәгать итә. Илдар һәм аның җитәкчелегендәге иҗат төркеме үз куллары белән сурәтләрне зур тукымага төрле төстәге акрил буяулары ярдәмендә төшерә. Бу рәсемнәр шәп һәм чыннан да бик оригиналь килеп чыга!

**– Бөтен кеше дә шагыйрь, язучы була алмаган кебек, рәсем ясау осталыгы да һәркемгә бирелми. Үзеңдә әлеге Ходайдан бирелгән сәләтнең барлыгын кайчан тойдың?**

- Дөресен әйткәндә, бу сәләтнең миңа каян килгәнлеген төгәл генә әйтә дә алмыйм. Чөнки (әтием – академик, әнием – бухгалтер). ле балалар бакчасына йөри башлаганчы ук, кәнфит кәгазендәге матур чеелән баласы рәсемен кәгазьгә төшергәнем истә. Кәнфит кәгазе һәм мин ясаган рәсемнәрне бер-берсеннән аерып булмый иде. Үсә төшкәч, махсус сәнгать мәктәбендә белем алдым. Әмма биредә укыганда, рәсем ясау минем өчен беренче урында түгел иде, шуңа мин укуны «өч»легә генә тәмамладым. Мәктәптән соң КАИга инженерлык юнәлеше буенча укырга кердем, тик бер елдан, кире уйлап, ТДГПУның рәсем сәнгате һәм дизайн факультетын сайладым.



**- Ни өчен нәкъ менә поп-арт стилендә иҗат итәсең һәм бу мавыгуың нидән башланды?**

- Миңа стрит-арт дип аталган сәнгать төре ошый. Бу - Англиядә киң таралыш тапкан, урам диварларына якты төсләр белән ясалган социаль эчтәлекле сюжетлы рәсемнәр. Әлеге төр бүген дә бик популяр. Һәр райтерның үз юнәлеше, тематикасы була. Өстәвенә, күптәннән графити, трафарет белән кызыксынып килдем. Шундыйрак үзенчәлекле стильдә эшләп карау теләге белән күптән янып йөри идем. Кулай сәбәп тә килеп чыкты: танышымның туган көненә оригиналь бүләк ясарга уйладым һәм... эшкә керештем. Бүләгемә туган көнен бәйрәм иткән дустымның гына түгел, ә башка танышларымның да исе китте. Тора-бара беренче клиентлар барлыкка килде: поп-арт портретларны заказга эшли башладым. Шуннан китте инде...

**- Иҗат һәм эшмәкәрлек арасындагы чикне табу җиңелме һәм синең өчен кайсысы мөһимрәк?**

- Миңа калса, бу ике төшенчәне капма-каршы кую дөрес түгел. Иҗат һәм акча бер-берсенә ярдәмләшеп яшәргә тиеш. Һәр хезмәтнең үз бәясе булу – гадәти күренеш, килешәсездер. Танылган Леонардо да Винчины гына алыйк. Ул да үз вакытында тормышын заказга картиналар иҗат итеп алып барган. Әмма аңа карап кына аның талантына, осталыгына бәя төшми.

**- Ә рәсемгә осталыгы булмаганнарны, мәсәлән, мине бу стильдә эшләргә өйрәтеп буламы?**

- Була, әлбәттә. Башка шәһәрләрдәге филиалларыбызда хезмәт куючыларның күбесе рәсем ясый белмиләр иде. Эш барышында без аларны бу һөнәргә скайп аша бик тиз өйрәттек..

**- Сез эшләгән поп-арт картиналар президент Рөстәм Миңнеханов һәм Казан мэры Илсур Метшинның (фотода) эш бүлмәсен бизи. Рус эстрадасы җырчылары Доминик Джокер, Полина Гагарина, Иван Дорн, Нойз МС, «Ленинград» төркемнәренә дә үз сурәтләре белән картиналар бүләк иткәнсең. Аларның мондый үзенчәлекле бүләктән алган тәэсирләре нинди булды?**

- Таныш булмаган кешегә үз сурәте төшерелгән картина бүләк итү сәер булып тоеладыр. Әмма бу – әлеге кешеләр белән танышу һәм аралашу өчен менә дигән мөмкинлек. Ә бүләккә карата реакциягә килгәндә, әлбәттә, «йолдызлар»ның барысы да шаккату хисе кичерде. Аларга бик ошады. Аеруча «Ленинград» төркеменә. Әлеге бүләктән соң, алар Мәскәү буенча поп-арт стилендә эшләнгән афишалар белән чыгыш ясады.

**- Күз алдыңа китер әле, Илдар бабайниләр белән шөгыльләнер икән? Бу хакта уйланганың бармы?**

- Бүген мин киләчәк өчен җитәрлек булган финанс базасын булдырырга уйлап торам. Ә аннан соң нинди дә булса социаль юнәлеш белән шөгыльләнер идем. Мин 3 ел буе балалар укыттым. Бәлки бу юнәлештә эшемне дәвам иттерермен. Нинди дә булса нәтиҗәгә ирешү өчен бит 365 көн эчендә 365тән артык хәрәкәт ясап карарга кирәк. Ә Илдар бабайга килгәндә, ул, әлбәттә, оныклар тәрбияләү һәм тормышның тәмен тоеп яшәү белән шөгыльләнәчәк.

**- Максатларыңны тормышка ашыруда уңышлар үзеңә, Илдар!**

### Белешмә

*Поп-арт - инглизчәдән «киң таралыш алган сәнгать» дигәнне аңлата. Англиядә барлыкка килеп, Америкада чәчәк алган 1950-1960 нчы еллар рәсем сәнгатендәге бер юнәлеш. Басым төрлелек, күңел ачу, якты төсләр белән эш итүгә ясала. Беренче поп-арт картина авторлары булып Питер Блек, Джо Тилсон һәм Ричард Смит таныла.*

• Сәламәтлек

# Җиһанда – алтын көз!

**Илмир ВӘЛИЕВ,** хәбәрче

Көзне «гүзәлләрнең гүзәле» дип йөртсәләр дә, әлеге ел фасылында сәламәтлеккә аеруча зур игътибар белән карарга кирәк. Җәйге эсседән салкын кышка күчә торган чор бит ул – көз.

Табигать кешене ышанычлы саклану механизмы белән бүләкләгән. Сүзем иммунитет турында. Иммунитет ярдәмендә без үз-үзебезне төрле инфекцияләрдән саклыйбыз, экстремаль шартларда да (мәсәлән, безнең якларда гадәттәге күренешкә әйләнгән кышкы салкыннар, түзә алмаслык эсселек) тормыш итә алабыз. Һава температурасының даими тирбәлеше инфекция таралуга уңай йогынты ясый. Көз – нәкъ менә шундый вакыт. Традиция буенча, без иммунитет турында авыруның беренче билгеләре беленә башлагач кына искә төшерәбез. Соңыннан, якын-тирәдә урнашкан даруханәгә барып, кыйммәтле дарулар өеме алып кайтып, терелмәкче булабыз.

Кызганыч, дөньяда могҗизалар юк. Иммунитетны һәрвакыт ныгытып, һәм «җимерелгән» урыннарын төзәтеп торырга кирәк. «Тынычлык телисең икән – сугышка әзерлән», дигән әйтемне хәтерлисезме?

Үз сәламәтлеген кайгыртмый торган кешеләр ник моны эшләмәүләренә мең төрле сәбәп таба. Иртән күнегүләр ясарга вакытлары юк. Витаминнар аларның ышанычларын акламый. Ә суган белән сарымсакны бөтенләй ашамыйлар. Бу исемлекне чиксез дәвам итеп була. Үзебезнең ялкаулыкны бераз алдап, бу өлкәдәге өстенлекләрне карап алыйк әле. Сәламәт булырга теләсәң, түбәндәге киңәш-табышларга колак сал.

### Һәрвакыт кулыңны ю!

Күпчелек грипп вируслары турыдан-туры, ягъни контакт аша күчә. Мәсәлән, сез куллана торган телефон яисә клавиатурадан авыру кеше дә файдаланып, вирус сезгә дә күчәргә мөмкин. Кул юарга мөмкинлек булмаса, һич югы, юеш салфеткалар белән сөртергә тәкъдим итәлә.

### Күп сыеклык эч!

Сыеклык организмны чистарта, төрле токсиннарны чыгара. Кеше көненә кимендә 2 литр күләмендә сыеклык эчәргә тиеш.

### Саф һава сула

Саф һавада йөрү – сәламәтлек чыганагы. Бүлмәләрне иртә һәм кич җилләтеп алырга кирәк. Сулау системасы кешенең иммунитеты белән бик тыгыз элемтәдә тора.

### Витаминнарга бай ризыклар белән туклан!

Болар арасына җиләк-җимеш, яшелчә керә. Көзге моңсулыкны җиләк-җимешләр белән бизә!

### Йогурт аша!

Күп тикшеренүләр нәтиҗәсендә, 1 стакан йогурт грипп авыруларына бирешүчәнлекне 25%ка киметкәне ачыкланган. Йогуртның файдалы бактерияләре иммунитетны баета. Йогурт файдалы гына түгел, ә белгәнебезчә, бик тәмле дә!

Һәм тагын бер киңәш: психологик халәт тә мөһим роль уйный. Мин авырыйм, дип уйласаң, нәкъ шулай була да. Иммунитетың көчле һәм сәламәт икән, бер авыру да, инфекцияләр дә куркыныч түгел.

Танылган немец язучысы Генрих Гейне әйткәнчә, «Мин белгән бердәнбер матурлык - саулык». Көзге яңгырлар кәефегезне төшермәсен, исәнлегегезне саклагыз.

• Спорт



# Минем арттан йөгер!

**Раил САДРЕТДИНОВ,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Сигезенче сентябрьнең матур, кояшлы көне Универсиада Авылында яшәүчеләр өчен иртәнге йөгерүдән башланып китте.

Студентларның иң яраткан көнен әйтимме? Үзең дә бик яхшы беләсеңдер әле. Әлбәттә, якшәмбе! Бу көнне һәркем атна буена туймаган йокысын туйдырырга, эшләнмәгән эшләрен башкарырга тырыша, ял итә. Без дә көнебезне файдалы эштән башлап җибәрергә булдык.

Чараның төп оештыручысы – Бөтенрәсәй «Минем арттан йөгер» яшьләр проекты һәм аның Казан шәһәрендәге бүлекчәсе җитәкчесе – Денис Волков. Чара – яшьләр арасында сәламәт яшәү рәвеше һәм дөрес туклану культурасын формалаштыруга юнәлдерелгән проект. Биредә катнашып, 16 яшьтән алып 30 яшькәчә һәрбер кеше сәламәт тормышка шәхси юл табу мөмкинлеге ала. «Минем арттан йөгер» проекты Россиянең сиксәннән артык төбәгендә үз бүлекчәләрен булдырган. Проект активында йөз меңнән артык кеше исәпләнә. Проектның иң актив шәһәрләреннән Камчатка һәм Чиләбе санала.

«Бүген яшьләр өчен бихисап проектлар тормышка ашырыла. Катнаш һәм үс кенә. «Минем арттан йөгер» проекты да шундыйлардан саналырга хаклы. Бүген, бик күп спорт корылмалары булуга карамастан, һәркемнең дә спорт белән шөгыльләнергә мөмкинлеге җитеп бетми. Я вакыт җитми, я башка сәбәпләр уйлап табабыз. Ә йөгерү исә һәркем дә шөгыльләнә ала торган спорт төрләреннән санала», – дип билгеләп үтте Денис Волков.

«Минем арттан йөгер» проекты бер йөгерү белән генә чикләнеп калмый, әлбәттә. Яшьләрне сәламәт яшәү рәвешенә өйрәтү максатыннан, проектта алга таба дөрес туклану буенча төрле мастер-класслар, күренекле спортсменнар белән очрашу, аларның уңыш формулалары турында сорашу, походлар һ.б. чаралар үткәрү күздә тотыла икән. Яңалыклар белән социаль челтәрдәге төркемдә дә танышып була.

DARELFӨNYN университет
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш.,
Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.